КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 7 сентябрь г.Казань № 796

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 17 август, 590 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 17 август, 590 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 7 август, 641 нче; 2019 ел, 16 апрель, 298 нче; 2019 ел, 13 сентябрь, 825 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның преамбуласында «2014 – 2021» һәм «2014 – 2020» саннарын шул ук эзлеклелектә «2014 – 2024» һәм «2014 – 2024» саннарына алыштырырга;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына 30 көн эчендә субсидия бирүгә заявка формасын расларга.»;

әлеге карар белән расланган Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибендә:

3 нче пунктта:

беренче абзацта «2014 – 2021» саннарын «2014 – 2024» саннарына алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле «ж» пунктчасын өстәргә:

«ж) Татарстан Республикасы продукциясен Россия Федерациясеннән читкә чыгару кысаларында предприятиеләрнең патент стратегияләрен тормышка ашыру буенча хезмәт күрсәтү.»;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Юридик затларның финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре түбәндәгеләр була:

хезмәт өчен түләү;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

физик һәм юридик затларның хезмәт күрсәтүләре, шул исәптән элемтә хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, коммуналь хезмәтләр, мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр һәм башка хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

мөлкәттән файдалану өчен аренда түләве;

командировка чыгымнары;

тикшеренү эшчәнлеген үткәрүгә һәм предприятиеләр өчен программа продуктлары, методик материаллар, локаль норматив актлар эшләүгә бәйле эшләр өчен түләү;

чыгым материаллары сатып алу;

интеллектуаль милек базарын үстерү буенча хезмәтләр күрсәтүгә бәйле компьютер, сервер, телекоммуникацион һәм башка җайланмаларны сатып алу һәм модернизацияләү;

интеллектуаль милекне халыкара саклау эшләрен оештыруга бәйле чыгымнар;

интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле башка чыгымнар.»;

5 нче пунктта:

өченче абзацта татар текстында «үзгәртеп оештыру, ябылу яки банкротлык процессында тормавын» сүзләрен «үзгәртеп оештыру, ябылу процессында тормавын» сүзләренә алыштырырга, «ябылу процессында тормавын» сүзләреннән соң «, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавын» сүзләрен өстәргә;

җиденче һәм сигезенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидия алучы түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

заявка бирү көненә уртача айлык эш хакын Татарстан Республикасы буенча эшкә сәләтле халык өчен билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән ким булмаган дәрәҗәдә тәэмин итә;

элегрәк бирелгән бюджет акчасын максатчан файдаланмауны һәм (яки) нәтиҗәсез файдалануны булдырмый;

бу Тәртипнең 3 нче пунктындагы «а» – «д», «ж» пунктчаларында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашырган очракта:

гамәлгә кую документлары нигезендә Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә, фәнни-техник эшчәнлекнең, шул исәптән

халыкара фәнни-техник хезмәттәшлекне гамәлгә ашырганда булдырылган нәтиҗәләрен саклауны һәм яклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыра, патент һәм маркетинг тикшеренүләрен, патент, фәнни-техник һәм технологик экспертизалар үткәрә;

заявка бирү көненә эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә кимендә биш еллык эш тәҗрибәсе бар;

предприятиеләрнең һәм оешмаларның фәнни-техник һәм мәгълүмат ресурслары белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт идарә функцияләрен гамәлгә ашыру; фәнни-техник эшчәнлек, авторлык хокукы, аудит, интеллектуаль милекне саклау һәм яклау өлкәсендәге эшчәнлек, нәтиҗәләрен исәпкә алу, саклау һәм алар белән идарә итү; фәнни хезмәт күрсәтү, фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләргә карата ISO 9001:2015 (ГОСТ ISO 9001 – 2015) таләпләренә туры килә торган сыйфат менеджменты системасы сертификаты бар;

Татарстан Республикасында Интеллектуаль милек федераль хезмәтенең (Роспатент) «Сәнәгать милке федераль институты» федераль дәүләт учреждениесенең вәкаләтле (терәк) оешмасы функцияләрен гамәлгә ашыра;

бу Тәртипнең 3 нче пунктындагы «е» пунктчасында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашырган очракта:

заявка бирү көненә кимендә өч еллык белем бирү чараларын үткәрү тәҗрибәсе бар;

Татарстан Республикасында Интеллектуаль милек федераль хезмәтенең (Роспатент) вәкаләтле (терәк) оешмасы тарафыннан интеллектуаль милек нәтиҗәләрен хокукый саклау һәм аларның нәтиҗәләрен файдалану мәсьәләләре буенча белемнәрне тарату юнәлеше буенча чараларны тормышка ашыру функцияләре гамәлгә ашыра.»;

7 нче пунктның сигезенче абзацында «а» – «д» пунктчаларында» сүзләрен «а» – «д», «ж» пунктчаларында» сүзләренә алыштырырга;

7 нче пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә, фәнни-техник эшчәнлекнең, шул исәптән халыкара фәнни-техник хезмәттәшлекне гамәлгә ашырганда булдырылган нәтиҗәләрен саклауны һәм яклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыруын, патент һәм маркетинг тикшеренүләрен, патентлар, фәнни-техник һәм технологик экспертизалар үткәрүен раслый торган документлар күчермәләре (шартнамәләр, башкарылган эшләр актлары);»;

11 нче пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 7 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.»;

12 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Субсидия бирү бюджет акчасы белән баш эш итүче һәм субсидия алучы арасында субсидия бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре;

бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыру шартлары һәм тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәләренең мәгънәләре;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисаплылык бирү тәртибе, вакытлары һәм формасы, субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү вакытлары һәм формалары (кирәк булганда);

субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылганда субсидияне кире кайтару очраклары;

бюджет акчасы белән баш эш итүче, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында субсидияләрнең файдаланылмый калган өлешләре торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеге турында һәм, әлеге карар булмаган очракта, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияне (субсидиянең калган өлешләрен) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару тәртибе һәм вакытлары турында нигезләмәләр;

субсидия алучы тарафыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны (югары технологияле чит ил җиһазы, чималы һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) тыю турында нигезләмә;

субсидия алучының һәм килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булган затларның бюджет акчасы белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан аларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә ризалыгы;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр;

кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен субсидия алучының җаваплылыгы;

бу Тәртипнең 17 нче пунктында билгеләнгән формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләре.

Кирәк булганда, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзелә.»;

түбәндәге эчтәлекле $12^1$ пункт өстәргә:

«$12^1$. Субсидия бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр була:

предприятиеләрнең интеллектуаль милкенә хокуклар белән идарә итү системаларын булдырган очракта – предприятиеләрнең интеллектуаль милкенә хокуклар белән идарә итү системаларын булдыруда катнашучы предприятиеләр саны;

«Татарстан Республикасының интеллектуаль потенциалы» мәгълүматлар банкы» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасын эшләгән һәм алып барган очракта – килешүдә билгеләнгән вакыт эчендә «Татарстан Республикасының интеллектуаль потенциалы» мәгълүматлар банкы» автоматлаштырылган мәгълүмат-аналитика системасын эшләү һәм аның эшләвен тәэмин итү;

интеллектуаль милек өлкәсендә төбәк үсеш стандартын эшләгән һәм әлеге өлкәдә иң яхшы тәҗрибәләр җыентыгын бастырып чыгарган очракта – интеллектуаль милек өлкәсендә эшләнгән һәм бастырып чыгарылган төбәк үсеш стандарты;

интеллектуаль эшчәнлекне инвентарьлаштыру, аңа экспертиза үткәрү, аның саклауга сәләтле нәтиҗәләрен ачыклау һәм аларны бәяләү, технологик инновацияләрне гамәлгә ашыру өлкәсендәге проблемаларны ачыклау, технологияләрне Россия һәм халыкара базарларга чыгару максаты белән предприятиеләрне тикшергән очракта – тикшерелгән предприятиеләр һәм оешмалар саны;

интеллектуаль милек мәсьәләләре буенча фәнни-техник, икътисадый һәм методик чараларда (форумнар, симпозиумнар, конференцияләр, семинарлар, күргәзмәләр, конкурсларда) катнашкан һәм аларны үткәргән очракта – фәнни-техник, икътисадый һәм методик чаралар саны;

интеллектуаль милек өлкәсендә белем бирү чараларын үткәргән очракта – интеллектуаль милек белән идарә итү өлкәсендә укуда булган белгечләр саны;

Татарстан Республикасы продукциясен Россия Федерациясеннән читкә чыгару кысаларында предприятиеләрнең патент стратегияләрен тормышка ашыру буенча хезмәт күрсәткән очракта – Patent Cooperation Treaty процедурасы буенча халыкара заявкаларны (Патентлар кооперациясе турындагы шартнамә нигезендә бирелгән) алга этәрү буенча хезмәт күрсәтелгән предприятиеләр һәм оешмалар саны.»;

14 нче пунктта:

беренче абзацта «субсидия алучыга» сүзләрен «субсидия алучыга (С)» сүзләренә алыштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«С = С_{су} + С_{бд} + С_{рс} + С_{ом} + С_{по} + С_{нтм} + С_{пс}\ ,»;$$

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«$С_{пс}$ – халыкара нормалар нигезендә Татарстан Республикасы продукциясен Россия Федерациясеннән читкә чыгару кысаларында предприятиеләрнең патент стратегияләрен тормышка ашыру буенча хезмәтләр күрсәтү өчен түбәндәге формула буенча билгеләнә торган чыгымнар:

$$С_{пс} = \sum С_{рпс} \times N,$$

монда:

$\sum С_{рпс}$ – халыкара шартнамәләр нигезендә сәнәгать милке объектларын саклауга бәйле гамәлләргә чыгымнарны, халыкара заявканы теркәүгә, халыкара экспертиза үткәрүне, гариза бирүченең үтенечнамәсе буенча милли заявка буенча халыкара төрне эзләүне, үтенечнамә канәгатьләндерелгән көннән 8 ай үткәнгә кадәр халыкара

төрне эзләү турында хисап бирүне, халыкара нормалар нигезендә заявкалар бирүгә бәйле пошлиналар өчен түләүне үз эченә ала алган предприятиеләрнең патент стратегияләрен тормышка ашыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә чыгымнарның гомуми суммасы,

N – әлеге чараны тормышка ашыруда катнашучы предприятиеләр саны.»;

17 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Субсидия алучы, хисап елыннан соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, бюджет акчасы белән баш эш итүчегә бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап һәм бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Субсидия алучы субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән өчен штраф санкцияләре кулланыла.

Штраф санкцияләре күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$A = \sum_{i=1}^{N} \left(1 - \frac{d_i}{D_i}\right) \times V,$$

монда:

N – субсидия бирү нәтиҗәләре саны;

$d_i$ – субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турындагы хисап нигезендә субсидия бирү i-нәтиҗәсенең ирешелгән мәгънәсе;

$D_i$ – субсидия бирү i-нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе;

V – субсидия алучы тарафыннан алынган субсидия күләме.»;

18 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Субсидия бюджет акчасы белән баш эш итүченең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан аларны биргәндә билгеләнгән, бюджет акчасы белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартларны бозганда;

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгәндә;

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар бирү факты билгеләнгәндә;

бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән субсидия бирү шартлары бозылганда;

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм өстәмә хисаплылык тапшырылмаганда;

субсидиядән максатчан файдаланылмаганда.»;

Тәртипкә 1, 2 нче кушымталар (карарга теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында
ХИСАП

Субсидия алучының исеме: ___________________________________________
Тапшыру вакыты: ____________________________________________________

| Т/с | Нәтиҗәнең исеме | Чараның исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификациясе буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Субсидия алучының җитәкчесе
(вәкаләтле зат) _________________________ _______________ __________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

20___ ел, «___» ___________

________________________________________

Юридик затларның Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып
субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында
ХИСАП

Субсидия алучының исеме: ________________________________________

Тапшыру вакыты: ________________________________________________

| Субсидия акчасын тоту юнәлеше* | Чыгымнарның функциональ классификациясе буенча коды | | | | Чыгымнарның икътисадый классификациясе буенча коды | Ел башыннан акча керде | Ел башыннан акча тотылды |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бүлек | бүлекчә | максатчан статья | чыгымнар төре | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

--------------------------------

*Хисапка чыгымнарның тотылышын раслый торган беренчел бухгалтерлык исәбе документларының күчермәләре теркәлә.

Субсидия алучының җитәкчесе
(вәкаләтле зат) ________________________ _______________ _________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

20__ ел, «___» ___________

_____________________________________